# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл жирлегенең Чүти торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**25 октябрь, 2019** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 22 октябрендә 13 сәгатьтә, 2019 елның 25 октябрендә 13 сәгатьтә, этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2020 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- материаллар сатып алып, урамнарны яктыртуны ремонтлау;
- материаллар сатып алып, буаны ремонтлау;
- материаллар сатып алып җәяүлеләр өчен күперләрне ремонтлау;
- материаллар сатып алып, кое һәм чишмәләр территориясен төзекләндерү;
-торак пунктның чүплекләре территорияләрен чистарту;
б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау;
в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:
- материаллар һәм җайланмалар сатып алып, зиратларның контейнер мәйданчыкларын ремонтлау;
- материал алып зират коймасы тоту .»

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 450 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -245, бу 54 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 245 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлегенең Чүти торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме

а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- материаллар сатып алып, урамнарны яктыртуны ремонтлау;

- материаллар сатып алып, буаны ремонтлау;

- материаллар сатып алып җәяүлеләр өчен күперләрне ремонтлау;

- материаллар сатып алып, кое һәм чишмәләр территориясен төзекләндерү;

-торак пунктның чүплекләре территорияләрен чистарту;

б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- материаллар сатып алып, сусаклагыч челтәрләрне ремонтлау;

в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:

- материаллар һәм җайланмалар сатып алып, зиратларның контейнер мәйданчыкларын ремонтлау;

- материал алып зират коймасы тоту » соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Чүти авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Чүти авыл җирлеге Башлыгы П.П.Тараканов